ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 169 от «17» 06 2019 г.

“Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018 ел, 25 декабрендә
кабул ителгән 611 нче санлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру " федераль максатчан программасы Концепциясен раслау турында” 2012 елның 27 октябрендәге 1995-р номерлы күрсәтмәсен, "2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру" Федераль максатчан программасы турында" 2013 елның 3 октябрендәге 864 номерлы РФ Хөкүмәте карарын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 ел, 6 декабрь, ПУ-1115 нче Указын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору дәүләт программасын раслау турында” 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче санлы карарын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 25 декабрендә кабул ителгән 611 санлы карары белән раслангаан “2019 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру” максатчан программасында һәм 1 нче кушымтадагы «Программа паспортында» «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл – транспорт һәлакәтләрен азайту һәм алар сала торган зыяннар авырлыгын киметү чараларын гамәлгә ашыру турында" 2017 елның 18 декабрендәге 1004 номерлы карарына сылтаманы төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерегә.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов